**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.05.2017 Балык Бистәсе штп. № 102пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 1 июлендәге 186-пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Халык катнашында сәяси чаралар иминлеген тәэмин итү турындагы законнарны үтәү турында» гы мәсьәлә буенча 2017 елның 25 апрелендәге, ПРА-10 ДСП номерлы эш киңәшмәсе нәтиҗәләре буенча йөкләмәләр исемлеген үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген төгәлләштерү һәм төзәтү максатларында, «Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 6.1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләрнең һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы якланганлыгы таләпләрен һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) иминлеге паспортларын раслау турында» 2015елның 25 мартындагы 272 номерлы карары, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук гражданнарның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы территориясендә урыннарның иҗтимагый-сәяси характерындагы актуаль проблемалар турында җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен махсус бирелгән яисә җайлаштырылган бердәм урыннарның исемлеген раслау турында» 2013 елның 6 августындагы 01-02/72 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 1 июлендәге 186пи номерлы карары белән расланган

(Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 мартындагы 42пи номерлы, 2016 елның 23 июнендәге 99пи номерлы, 2017 елның 2 маендагы 88пи номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 35-36 пунктлар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «35 | Иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемалар буенча җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен махсус бирелгән яисә җайлаштырылган урын Балык Бистәсе ш. т. п. Набережная урамындагы сквер территориясендә иҗтимагый-сәяси характердагы урын | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Яр буе ур. | 1 |
| 36 | Бәйрәм чараларын үткәрү өчен махсус билгеләнгән урын («Мәйдан») Балык Бистәсе ш. т. б. Новая урамы (татар халык бәйрәме Сабантуй үткәрү территориясе) | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Новая ур. | 1» |

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы ,Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин